“ Әдәби мирас” музее- тәрбия учагы

Хәерле көн, хөрмәтле тыңлаучылар. Мин сезгә Лениногорск шәһәре 4нче урта мәктәбендә “ Әдәби мирас” музееның барлыкка килү тарихын сөйлим.

1958 елда яшь язучы һәм журналист Шамил Бикчурин Лениногорск шәһәрендә әдәби түгәрәк оештырып, аның беренче утырышын уздыра. Бу утырыш «Ильич васыятьләре» газетасы редакциясенең бер кечкенә бүлмәсендә була. Анда Ш.Бикчуриннан кала, газета редакторы Бастам Сәлахов, яшь язучы Әсрар Галиев һәм әле бер әсәр дә иҗат итмәгән ике-өч иптәш кенә катнаша. Бу берләшмәне “ Чишмә” иҗат берләшмәсе дип атыйлар. Сез стендда бу фотографияне күрәсез.

«Чишмә» әдәби оешмасының беренче җитәкчесе Шамил ага Бикчурин нефтьчеләр турында яза һәм «Каты токым», Тирән катлам» романнарын иҗат итә. Бу әсәрләрнең зур татар әдәбиятында үз урыннары бар.

Романдагы образларның прототиплары, кара алтын табучылар, күбесе безнең арада яши. Алар 4 мәктәп укучыларының әби- бабалары. Бу романнарның иң беренче каралама нөсхәсе, мөхтәрәм язучыбыз тарафыннан язылган кулъязмалар бу музейда саклана. Шамил Бикчурин, Гәрәй Рәхим СССР Язучылар берлегенә алыналар Бүген «Чишмә» иҗат оешмасы лаеклы рәвештә Шамил Бикчурин исемен йөртә.. Әйе, Шамил Бикчурин җитәкчелегендә, дүрт-биш кеше катнашында башланып киткән «Чишмә» берләшмәсе бүген зур оешмага әйләнде.

Анда катнашкан фронтовик шагыйрь Рамазан Байтимеровның шигыренә. күренекле композитор Рөстәм Яхин Татарстан Гимнын иҗат итте..

Безнең мәктәп укучылары күп кенә эзләнүләрдән соң шәһәребездә Ш.Бикчурин премиясенә лаек булган кешеләр барлыгын белде. Без аларның кулъязмаларын, шәхси әйберләрен җыя башладык. Шулай итеп мәктәбебездә “ Әдәби мирас” музее туды.

«Чишмә» әдәби оешмасы көннән-көн танылу ала, яшь талантларны ачыклый. Оешкан көненнән алып, шәһәр һәм авыл мәктәпләре белән эшләп, очрашулар оештырып, яшь Тукайларны эзли,.шәһәр һәм район халкына күптөрле әдәби-мәдәни чаралар тәкъдим итә.

Әдәби оешманың яшәешен тәэмин итеп, Татарстан күләмендә танылу алган әдипләр Шамил Бикчурин, Рәшит Шиһап, Җәүдәт Дәрзаманнарның каләмдәше, утыз елга якын әдәби берләшмәне җитәкләгән шагыйрь һәм композитор, сәләтле оештыручы һәм укытучы Разим Вәлиуллин аеруча зур тырышлык куйды. Барыбызның да күз алдыбызда: байтак еллар Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген, шулай ук Композиторлар берлегенең Әлмәт бүлеген (үзе аны оештыручы да) җитәкләгән Разим Вәлиуллин – Лениногорск җирлегендә, Шөгер төбәгендә чын мәгънәсендә моң булып сибелгән шәхес, һәм аның

биниһая фидакарьлеген бәяләмәскә, аны онытырга хакыбыз юк! Шамил Бикчурин исемендәге әдәби иҗат оешмасының исеме җисеменә тиң! Ул үз эченә каләмдәшләрен, композиторларны, җырчыларны һәм рәссамнарны берләштерде. Композиторлар Разим Вәлиуллин, Фәйзи Хөснуллин, Каюм Шәрәфов, Тәлгать Әхмәтшин, җырчылар Фәнис Йосыпов, Минәхмәт Фәйрушин, Ринат Хәбипов һәм башкалар армый-талмый халыкка хезмәт иттеләр һәм итәләр.